Г.Ә. Нәбиуллина

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АФОРИЗМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Һәр халыкның тормыш, белем һәм акыл тәҗрибәсе хикмәтле сүзләре рәвешендә гасырлар дәвамында тупланып, буыннан-буынга күчеп сакланып килгән. Хикмәтле сүзләрнең күбесе мәкаль-әйтемнәр булып халык авыз иҗаты җыентыкларында беркетелгән. Язма әдәбият барлыкка килгәннән соң, хикмәтле сүз әйткән акыл ияләренең исемнәре дә теркәлеп бара. Борынгы төрки язма истәлекләрдә, М.Кашгариның “Диване-лөгат-эт-төрк” сүзлегендә һәм Й.Баласагунлының “Кутадгу билик” поэмасында аларның зур урын алуы мәгълүм. Урта гасырлардан алып хәзерге чоргача дәвердә иҗат иткән язучы-шагыйрьләрнең иҗатында, аерым алганда, Йосыф Баласагунлы, Сәиф Сараи, Мөхәммәдьяр, Каюм Насыйри, Риза Фәхреддин, Габдулла Тукай, Дәрдмәнд, Һади Такташ, М. Җәлил, Г. Кутуй, Х. Туфан һ.б. әсәрләрендә халкыбызның тормыш һәм яшәү рәвешен, зирәклеген, дөньяга карашын чагылдырган хикмәтле сүзләр, ягъни афористик гыйбарәләр киң кулланылалар.

Классик дәвердә һәм хәзерге татар әдәбиятында күренекле язучы һәм шагыйрьләребез Ә. Еники, Гамил Авзал (1921), А. Гыйләҗев, Гариф Ахунов (1925), М.Мәһдиев. Әхсән Баян (1927), Мөсәгыйт Хабибуллин (1927) Миргазиян Юныс, (1927), Туфан Миңнуллин (1935), Мәдинә Маликова (1935) Тәлгат Галиуллин (1938), Фәнис Яруллин 1938), Рәдиф Гаташ (1941), Айдар Хәлим (1942), Равил Фәйзуллин (1943), Харрас Әюп (1946), Зөлфәт (1947), Флүс Латыйфи, Рафаэль Сибат, Разил Вәлиев (1947), Зиннур Мансуров, Роберт Миңнуллин (1948), Камил Каримов (1950), Мөдәррис Вәлиев (1953), Нәбирә Гыйматдинова (1956), Газинур Морат (1959) һ.б. әсәрләрендә тирән мәгънәле, фәлсәфи эчтәлекле гыйбарәләрне күп очратырга мөмкин Инде килеп Ш.Галиев, Рабит Батулла, М.Галиев, М.Мирза, З.Хәким кебек киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм язучы, шагыйрьләребезнең тапкыр-зирәк сүзләрне, акыллы гыйбарәләрне максатчан иҗат итүләре һәм теркәп-беркетеп барулары мәгълүм.

Исемнәре билгеле хикмәтле сүзләрне канатлы сүзләр, гыйбарәләр, юмор һәм ирония белән әйтелгәннәрен төрткеләр дип тә йөртәләр, соңгы вакытта аларны афоризмнар дип әйтү гадәткә кереп бара. Бүгенге көндә татар әдипләренең иҗат иткән әсәрләре аша зирәк, тапкыр, хикмәтле сүзләрен, ягъни афоризмнарын җыю, теркәү, җыентыклар төзү өстендә эш алып барыла. Шул уңайдан ике хезмәтне - "Мәгариф" нәшриятында басылган "Татар акылы" (Альберт Яхин. Казан, 2002) һәм "Мин әйттем: татар язучыларының афоризмнары, хикмәтле сүзләре, фәлсәфи уйланулары" дип аталган (Тәз. Г.Ә.Нәбиуллина һәм Л.Г.Гыйләҗева, Казан, 2008) җыентыкларын әйтеп узарга кирәк. Бу җентыкларда әдәби хәзинәбездән, ягъни борынгы гомумтөрки һәм урта гасырлардан алып хәзерге чорга кадәр яшәп иҗат иткән язучы-шагыйрьләрнең әсәрләреннән бертеклэп җыелган күпсанлы афоризмнары туплап бирелә.

Җыентыкларда урын алган афоризмнарның эчтәлегеннән һәм безнең тикшеренүләребездән дә күренгәнчә, афоризмнар иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр, яшәеш кыйммәтләре, әхлакый төшенчәләргә бәйле проблемаларны яктырта. Тормыш-яшәешнең төрле ягына караган тема-проблемаларны иңләп үтә торган мәсьәлә – ул милләт язмышы. Күрәсең, фаҗигале язмышка дучар булган татарның һәр әдибе милләтнең бүгенгесен һәм киләчәген читләтеп уза алмый. Шуңа да безнең халыкта Халык, милләт, сәясәт, тел, моң, хәтер кебек темаларга афористик гыйбарәләр күләме ягыннан да, үткенлеге һәм кискенлеге, җан авазы булып яңгырашы белән дә аерылып торалар. Тукай һәм Исхакыйлардан алып бүгенге әдипләребез иҗатында чагылыш тапкан әлеге сорауга җавапны Туфан Миңнуллин кыска итеп болай дип әйтә: "*Әгәр милләтеңне көчле итеп, бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан".* Р. Зәйдулланың "*Коллар без – үзара хан булып кыланабыз, үзебез ятлардан телебезне теләнәбез*" , Газинур Моратның "*Ирек яуларга да хокук кирәк, Сорап алып булмый ирекне"* дигән фикерләрен сызланмыйча укып булмый.

М. Галиевнең *"Тел – ул халыкның рухи дәвасы*" Мөдәррис Әгъләмовның "*Хәтер – синең киләчәгең дә*", Р. Фәйзуллиннның "*Арысланнар йөрми көтү*

*белән*", Ф. Яруллинның "*Язмыш арба, гел шуны тартып йөрисең, кая гына барма*" Ә.Гаффарның *"Яшәү – тауга менү",* Харрас Әюпның *"Безнең өчен иман шулдыр – бу дөньяның карасына мана-мана, җаның агарт"* М. Мирзаның "*Ерак үткәннәргә хәтердә булса да кайтып була, Ерак киләчәккә барыр өчен хыял гына җитми*" кебек уйлануларында тормыш-яшәеш үзенең бөтен каршылыгында, катлаулылыгында күз алдына килеп баса.

Татар әдипләре кешегә гаять зур игътибар бирә; шәхес, язылган һәм язылмаган кануннар хакында уйлана. Бу яктан үзенең үткенлеге һәм таләпчәнлеге белән сискәндереп җибәргән А.Гыйләҗевнең *"Кеше гаепсез булса, узган гомере турында уйлап та карамас иде",* Т.Галиуллинның *"Һәр кешедә әллә ничә мин утыра", яисә* Шәүкәт Галиевнең *""Үзеңне җиңү – иң зур җиңү, монда җиңелүче юк"* Разил Вәлиевнең *"Бөекләр күп сөйләшми;* З.Хәкимнең *"Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ясалмалылыгы гына ясалма түгел"* кебек фикерләренә беркем дә битараф кала алмыйдыр.

Афористик гыйбарәләр арасында аеруча зур урын бирелгән тагын бер тема – әхлакый кыйммәтләр. Татар халкы – горурлык, абырлык, ярдәмчеллек, чисталык ярату, гыйлемгә омтылу һ..б. сыйфатлары белән үзенә хөрмәт казанган халык. Шул ук вакытта мин-минлек, икейөзлелек, ваемсызлык һ.б. аны тарката, көчсезләндерә. Болар барысы да афоризмнарда ярылып яталар. Мәсәлән, Марсель Галиевтән *"Горурлык – күңелең ауганда да аумый торган текә манара йөртү",* Мөхәммәт Мирзадан *"Гадилек – һәркем күтәрелә ала, әмма һәркем шунда кала алмый торган биеклек"* Рабит Батулладан *"Әрсез, әрләгән саен, әрләндәй сикерә"*.

Татар афоризмнарында гомуми иҗтимагый мәсьәләләр белән бергә гаилә, хатын-кыз, ир-ат, мәхәббәт, бәхет, акыл-гыйлем, гаделлек-ялган һәм башка шундый мәңгелек фәлсәфи төшенчәләр дә яктыртыла. Р.Фәйзуллинның *"Кешенең иң зур иреге – сөюе, сөюлүе"* дигән афоризмы мәхәббәткә мәдхия булып яңгыраса, Гамил Авзал сүзләреннән хатын-кыз һәм ир-атның тормыштагы урыннарын чамаларга мөмкин "*Ничек итеп алга барырга дип, бичара ирләр ут йота, Дөньяны хатыннар белән сыерлар тота"*.

Афоризмнар, хикмәтле фикерне үтемле итеп җиткерү максатыннан булса кирәк, кыскалыкка, җыйнаклыкка омтылалар. Һәм кыскалык – әлеге тел җәүһәрләренең формалашуында төп билгеләрнең берсе. Болардан тыш, аларга фәлсәфилек, сәнгатьлелек (троплар һәм стилистик фигуралар куллану), көтелмәгән хөкем, катгыйлык, тотрыклылык, гомумиләштерү кебек сыйфатлар хас. Тәэсир итү көче, катлаулы күренешләрне үткен итеп чагылдыру, фикерне тыгыз итеп бирү мөмкинлеге афоризмнарның мәкальләргә шактый якын булуларын күрсәтә.

Шунысына да ачыклык кертү кирәктер: афористик гыйбарәләр һәм афоризмнар бар. Аларның аермасы нәрсәдә соң? Афоризмнар эчтәлеге белән тыгыз, кыска бер җөмлә калыбында әйтеләләр. Кайбер хикмәтле сүзләр исә бер җөмләгә генә сыешмыйча, берничә җөмлә белән бирелеп, бер өзек, абзац булып оешалар. Һәм аларны икенче төрле афористик гыйбарәләр дип атыйлар да инде. Мәсәлән, *Тормыш мәшәкатьләре — җилкәгә салынган ташлар кебек. Ләкин алардан котылу да, котылырга тырышу да юк. Алар минем өчен — сәгать герләре. Шулар йөртә сәгатьне һәм... кешене. Алар булмаса, йөрүдән — яшәүдән — туктар идек (Ә. Баян).*

Газета, журнал битләрендә дөньякүләм танылган сәясәтчеләрнең, философларның, язучыларның, фән эшлеклеләренең рус яисә башка бер чит телдән тәрҗемә ителгән **афоризмнар** күп кулланыла.. *Теләсә кемне дус иткәнче – ялгыз бул син, Теләсә нәрсә ашаганчы – ач тора бел (Г.Хайям).*

Афоризмнарның кайберләре еш кына мәгънәви һәм структур тәзелеше белән фольклор һәм таныш булган әдәби цитаталарны хәтерләтәләр, һәм, кайберләре безгә таныш халык мәкальләрен үзгәртеп тәзү нәтиәәсендә ясалалар. Мәсәлән*, Чыпчыкка да бер Ватан, Лачынга да бер Ватан (Ш. Галиев); Эт каргышы бүрегә төшми (Гамил Афзал); Күктәге айны күлдән эзләмиләр (М.Хәбибуллин); Күп уйнасаң, кәйнеәң дә төсе уәа (Хәсән Сарьян).*

Күренгәнчә, фәлсәфи фикерләүнең иң борынгы формаларыннан берсе булган афоризмнар билгеле бер чорның проблемаларын, халык тормышының фәлсәфәсен күзалларга ярдәм итәләр. Формасы белән җыйнак, эчтәлеге белән тирән мәгънәгә ия бу гыйбарәләр вакыт агышын тоярга, халыкның гасырлар дәвамында формалашкан иҗтимагый-фәлсәфи фикер тарихын, әхлакый-этик кануннарын, дөньяга карашын, яшәеш кыйммәтләренә мөнәсәбәтен үсештә-үзгәрештә күзалларга да мөмкинлек тудыралар.

Әдәби хәзинәбезне өйрәнеп, афористик гыйбарәләрне туплау эшен күләмле һәм дәвамлы эш итеп карарга кирәктер.  Булган тупланмалар белән генә чикләнеп калмыйча, киләчәктә афоризмнарның киңрәк һәм тулырак рәвештә яңа басмаларын эшләү дә күздә тотыла. Иҗаты белән афоризмнарга бай язучы-шагыйрьләребез  Ш.Галиев, Р. Фәйзуллин, Т. Миңнуллин, Т. Галиуллин, Р.Батулла Р. Вәлиев, М.Галиев, М.Мирза һ.б. хикмәтле сүзләрен, гыйбарәләрен, фәлсәфи трактатларын үз эченә алган махсус афоризм җыентыкларын төзү теләге дә юк түгел. Мондый хезмәтләрне булдыру татар халкының зирәклеген, тел һәм иҗат байлыгын, фәлсәфи фикер хәзинәсен барлау һәм туплауда, бүгенге һәм киләчәк буыннарга җиткерәдә әһәмиятле эш булып тора.